«Раслыйм»
Комисссия рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары

______________________________

П.Б.Емельянов

№ 14
07.02.2024 ел

# НӘТИҖӘ

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Татар Сарсазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары турында

**07.02.2024 ел** **Татар Сарсазы**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы инициативасы буенча ачык тыңлаулар «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»24.01.2024 ел, 18 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы карары белән билгеләнде,

26.01.2024 елның 03 нче номерлы «Чистай хәбәрләре» газетасында бастырылган (халыкка чыгарылган) 07.02.2024 елда Татарстан Республикасы Татар Сарсазы авыл җирлеге мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Сарсазы авылы, Үзәк урам, 13 нче йорт адресы буенча уздырылган.

Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә: Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Сарсазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын тикшерү.

Җәмәгать тыңлаулары үткәргән оештыру комитеты:

| | |
|---|---|
| П.Б.Емельянов | комисссия рәисе урынбасары, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| С.С.Мусин | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге башлыгы |
| А.А.Шумилов | Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, баш архитектор; |
| В.О Маркин | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «ГиИР» МБУның төзелеш контроле бүлеге |

җитәкчесе урынбасары.

Рәислек итүче: Емельянов П.Б. – оештыру комитеты рәисе урынбасары, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары;
Сәркатип: В.О. Маркин – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «ГиИР» МБУның төзелеш контроле бүлеге җитәкчесе урынбасары.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны) 10 кеше.

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты:**

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Сарсазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын хупларга.

2.Каралган мәсьәләне тиешле карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының чираттагы утырышында көн тәртибенә кертергә.

3. Җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәсе Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

риза 10 (кеше)
каршы 0 (кеше)
тавыш бирүдән тыелучылар 0 (кеше)

Рәис урынбасары: П.Б.Емельянов

Сәркатип: В.О.Маркин